ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2020 № 363

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы җирлекләре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2017 елның 24 июлендәге 891 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»» 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары, Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарына кабул итү турында» 2016 елның 22 апрелендәге 60 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы җирлекләре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктындагы 3 абзацының 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган, күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә нигезендә торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яисә күпфатирлы

йортлар белән идарә итү эшчәнлеге буенча башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан гамәлгә ашырыла башлады;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Ф. Нургаяновка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Нуриев